ГЛАВА ВАХИТОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ВАХИТОВ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

12.10.2022 д. им. М. Вахитова № 7

Югары Ослан муниципаль районы Вахитов авыл җирлегенең Бакча-Сарай авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003нче елның 6нчы октябрендәге131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004нче елның 28нче июлендәге Татарстан Республикасы Законының 35 ст., Югары Ослан муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Уставының 24 ст. нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. Югары Ослан муниципаль районының Вахитов авыл җирлегенең Бакча-Сарай бистәсендә 2022 елның 31 октябрендә 9.00 сәгатькә гражданнар арасында үзара салым җыюның беренче этабын билгеләргә.
2. Югары Ослан муниципаль районының Вахитов авыл җирлегенең Бакча-Сарай бистәсендә 2022 елның 31 октябрендә 11.00 сәгатькә гражданнар арасында үзара салым җыюның икенче этабын билгеләргә.
3. Югары Ослан муниципаль районының Вахитов авыл җирлегенең Бакча-Сарай бистәсендә 2022 елның 31 октябрендә 13.00 сәгатькә гражданнар арасында үзара салым җыюның өченче этабын билгеләргә.
4. Югары Ослан муниципаль районының Вахитов авыл җирлегенең Бакча-Сарай бистәсендә 2022 елның 31 октябрендә 15.00 сәгатькә гражданнар арасында үзара салым җыюның дүртенче этабын билгеләргә.
5. Халык исемлеген бүлү территориаль билге буенча башкарыла.

1 этап: Бакча-Сарай поселогының Дальняя, Приволжская урамнарында яшәүчеләр

2 этап: Бакча-Сарай поселогының Үзәк урамында яшәүчеләр

3 этап: Бакча-Сарай поселогының Нагорная ур., Яшьләр урамнарында яшәүчеләр

4 этап: Бакча-Сарай поселогының Лесная урамында яшәүчеләр

6.Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«2023 елда Югары Ослан муниципаль районының Вахитов авыл җирлеге Бакча-Сарай авылы территориясендә теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә

алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча юнәлдерү белән килешәсезме:

- Бакча-Сарай бистәсендә спорт-уен мәйданчыгы төзү

«ӘЙЕ» «ЮК»

7. Халык җыеннарын үткәрергә:

1 этап: Бакча-Сарай поселогы Приволжская урамы буенча 8нче номерлы йорт янында

2 этап: Бакча-Сарай поселогы Үзәк урамы буенча 11-нче номерлы йорт янында

3 этап: Бакча-Сарай поселогы Нагорный урамы буенча 5-нче номерлы йорт янында

4 этап: Бакча-Сарай поселогы Лесная урамы буенча 10-нчы номерлы йорт янында

8. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Югары Ослан муниципаль районы
Вахитов авыл җирлеге башлыгы Ф.Р.Каримов